46. *Rossiiskie fol`kloristy`: spravochnik* (1994) [Russian Folklorists: A Reference Book]. Tsentr traditsz. rus. kul`tury` “Preobrazhenskoe”, Arkh. “Fol`klor Rossii”; sost. L. V. Ry`bakova. 206 p. Moscow, Indrik. (In Russian)

# МАРСЕЛЬ БАКИРОВНЫҢ ИҖАДИ ПОРТРЕТЫ АНЫҢ ШӘХСИ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ КӨЗГЕСЕНДӘ ҺӘМ ЗАМАНДАШЛАР БӘЯЛӘВЕНДӘ

**Гүлшаһ Йылмаз,**
Афьон Коджатепе Университеты,
Turkey, 0300, Afyonkarahisar/Center,
gulsahyilmaz4048@gmail.com.

**Фәнзиля Хәким кызы Җәүһәрова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
zavgarova@inbox.ru.

**Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы Хәбетдинова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
mileuscha@mail.ru.

Мәкаләдә танылган фольклорчы, филология фәннәре докторы, профессор Марсель Хәернас улы Бакировның (1933) тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган фәнни хезмәтләр даирәсе системага салына. Аның фәнни һәм иҗади эшчәнлеге төрле яклап ачыла. Тикшеренү биографик һәм мәдәни-тарихи ысул ярдәмендә алып барыла. Мәкаләдә галим турында хезмәтләр библиографиясе формалаштырылган.

**Төп төшенчәләр**: Татарлар, татар галимнәре, фольклористика, Марсель Бакиров, Казан университеты

## Кереш

Хәзерге вакытта гуманитар фәннәр өлкәсендә кешенең шәхес буларак формалашуына, аның тарихи чынбарлыкта һәм җәмгыятьтә тоткан урынына зур игътибар бирелә. Мондый тикшеренүләрнең бер юнәлеше – галимнәрнең биографиясен өйрәнү. Галимнең шәхесе белән чор арасындагы бәйләнеш, кагыйдә буларак, шәхси тормышы вакыйгалары, ул вакыйгаларга дәлил рәвешендә бәяләнерлек чыганаклар аша билгеләнә, ә ул чыганаклар «үзенә» генә түгел, ә «башкаларга» да кагыла ала. Тарихның һәм үткәннең социомәдәни үлчәмнәрендә кешегә карата игътибар белән бергә бу чыганакларның әһәмияте дә арта.

Шәхси чыганаклар дигәндә, галим тормышының кайбер этапларына бәйле документлар, аның белән аралашканнарның, шул исәптән галимнәрнең дә, истәлек-хатирәләре була ала. Алар галим яшәгән чорның тарихи-мәдәни чынбарлыгы портретын сурәтләү мөмкинлеген бирәләр, шуның бәрабәренә кызыксыну уяталар. Мондый чыганакларны өйрәнү – шул чордагы фәнни даирәнең тарихи этапларын бәяләү чикләрен киңәйтә. Алар чор вәкилләренең тарихи вакыйгаларны кабул итүләрен, аларга бирелгән бәяләр палитрасын өйрәнүдә төп фактик дәлил буларак чыгыш ясыйлар, тикшеренүчеләргә башка чыганакларда булмаган кыйммәтле детальләр һәм чор үзенчәлекләрен билгеләү мөмкинлеге бирәләр. Бу документлардан алынган мәгълүмат фән кешесенең эчке дөньясын, фәнни максатларга ирешү юлындагы мотивларын күрергә, аңларга, аның тикшеренү лабораториясен, шулай ук башка социаль рольләрдә танылган галим образын формалаштырырга мөмкинлек бирә.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Әлеге тикшеренү эше танылган фольклорчы, тюрколог, әдәбият теориясе белгече, галим Марсель Хәернас улы Бакиров шәхесенә бәйле башкарыла. М.Х. Бакиров – XX гасырның икенче яртысыннан алып XXI гасырның беренче чирегенә кадәрге диярлек вакыт аралыгында хезмәт куйган талантлы фән эшлекләләре плеядасы вәкилләренең берсе. Алар – Татарстан Республикасы гуманитар фәннәренең үсешенә көчле импульс бирү белән беррәттән, төрки фәннәргә зур тәэсир ясаган галимнәр. М.Х. Бакиров 500 фәнни һәм әдәби – тәнкыйди басма мәкаләләр, шул исәптән 8

монография, уку һәм методик әсбаплар, фольклор җыентыклары авторы. Галимнең төп хезмәтләре шигырь теориясенә [1], [2], [3], [4], [5], татар фольклорына, [6], [7], [8], [9], [10], [11], төрки, шул исәптән татар теле тарихының тирән катламнарын өйрәнүгә багышланганнар [12], [13]. Татар фольклоры буенча рус телендә нәшер ителгән уку әсбаплары чит телле аудиториядә милли мәдәниятне алга сөрүгә ярдәм итә торган бердәнбер хезмәт дисәк тә, хата булмас.

Галим үзе дә, аның тикшеренү ысуллары, предметы да фәнни даирә өчен шактый кызыклы. Моны аның эшчәнлеге хакында абруйлы экспертлар тарафыннан әзерләнгән фәнни мәкаләләр дә раслый [14], [15], [16], [17], [18], [19], [20], [21], [22], [24], [25], [26]. Фольклорчы галимнең ачышлары киң катлам укучыларны да битараф калдырмаган (Кар.: [27]). Марсель Бакировның шәхесе, фәнни күзаллау киңлеге шәкертләре һәм танылган язучылар каләме белән дә ачылган [28], [29], [30]. Безнең бүгенге тикшеренүебездә төп урынны галимнең автобиографик рухта иҗат ителгән хезмәтләре алып тора. Алар шәхес турындагы мәгълүматларны, хезмәтләре библиографиясен системага салу мөмкинлеген бирә [31], [32]. Бу уңайдан без «Казан утлары» журналында «Кара таплы бәхет» исеме белән дөнья күргән автобиографик бәянны да атап китү дөрес булыр, дигән фикердә. [33], [34]

Әлеге тикшеренүләр биографик, мәдәни-тарихи ысуллар ярдәмендә башкарылды.

### Фикер алышу

Әдәбият белгече Й. Г. Нигъмәтуллина фикеренчә, әгәр язучының иҗади шәхесен системалы караш яктылыгында бәяләсәк, ул «катлаулы, күп дәрәҗәле структурага ия» булып чыга. (Тулырак кар.: [35]) Бу структураны аңлау өчен башлангыч момент булып, шәхесне «персонификацияләнгән эшчәнлек» буларак күзаллау тора (Тулырак кар.: [36]). «Сәнгатькәрнең иҗади процессындагы активлыгы сыйфат ягыннан төрле дәрәҗәләрдә дөньяны тою һәм дөньяга караш дәрәҗәсендә күренә» [37, 74 б.].

Марсель Бакировка багышланган әдәби портретларны анализлаганда, галим-тюрколог һәм язучы турында сюжетка кертелгән тотрыклы мотивлар яки образ элементлары комплексын табарга мөмкин. Беренче чиратта, каләмдәшләре, якташлары тарафыннан иҗат ителгән әлеге әсәрләрдә укучы игътибарын нәрсә җәлеп итә соң? Безнеңчә, аңа хас көч, куәт, кодрәт, үҗәтлек, сәламәтлек, иман, түземлелек, сабырлык, мәхәббәт.

«Марсель Бакиров тынычланып, туктап кала торганнардан түгел. Бу шәхес кимендә 43 градуслы темперамент һәм туктаусыз ашкынулар белән яши», – дип яза аның турында якташы язучы Фоат Садриев [29].

«Марсель Хәернас улы – киң кырлы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, профессор, филология фәннәре докторы, күренекле фән эшлеклесе, Россия Гуманитар Фәннәр академиясенең академигы, Россия Федерациясенең югары профессиональ белем бирү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре дәрәҗәсенә лаек булган шәхесләрдән. Гомер юлларын татар әдәбияты, мәдәнияте, сәясәте өлкәләрендә хезмәт итүгә багышлаган күренекле милләттәшләребез арасында Марсель абыйның әдәбият белеме, шигырь төзелеше, татар фольклорына кагылышлы мавыктыргыч дәресләрен тыңлаганнар саны да берничә меңнән артадыр. Миңа калса, ул һәр шәкерте хәтерендә нәзакәтле юмор остасы, киң эрудицияле галим, һәркем белән дустанә мөнәсәбәт кора белүче татар агасы буларак сакланадыр», – дип яза аның турында хезмәттәше Фәнзилә Җәүһәрова. Шулай ук ул аның татар фольклорын, милли рухны саклауга зур үҗәтлек белән тотынып, мәдәният хезмәткәрләре өчен халкыбызның йола иҗатын саклауга юнәлтелгән дистәдән артык сценарийлар иҗат иткәнен дә билгели [16].

Танылган шагыйрь, прозаик Марсель Галиев та остазы турында: «Марсель Бакиров җайлы аралашучан, шаяртырга яратучан», – дип яза. [28].

Казан университеты профессоры Гомәр Саттар-Муллиле үзенең багышлау шигырендә хезмәттәшен болай сурәтли:

Беркем әйтмәс: «Марсель эш сөйми»,
Әйтеп булмый аңа карт диеп,
Инде җиткән, өйдә ят диеп.
Ул һәрчакта мәшгуль эш белән,
Папка, портфель тоткан, еш күрәм,
Дәрт-дәрман да әле җитәрлек,
Яшь ханымнарны гашыйк итәрлек. [32, 466 б.]

Гомәр Саттар-Муллиле Марсель Бакировның хезмәт сөючәнлегенә чын күңелдән соклана. Аның тормыш һәм иҗат юлын гөрләп янган учак белән чагыштыра:

Коллегабыз яши беләдер,
Яшьнәп, янып эшли бирәдер [32, 466 б.].

Гомәр Саттар-Муллиле фикеренчә, хезмәттәшенең иҗат агачы мул җимешләр бүләк иткән. Галим, Марсель Бакиров гасырлар тирәнлегендә формалашкан серләрне чишә ала, дип билгели.

Галимгә багышланган мәкаләләрнең тагын бер уртаклыгы – аның авыр тормыш юлы мотивы. Бала чактан бирле озатып килгән авырлыклар аша үтеп, М. Бакиров бай тормыш тәҗрибәсе туплый алган. «Кара таплы бәхет» автобиографик бәянында М.Х. Бакиров беренче тапкыр үзенең шәҗәрәсе белән уртаклаша: «Әтием Хәернас Бәхранур улы (1898 елгы) атасы ягыннан да, анасы ягыннан да – укымышлы нәселдән. Бәхранур бабамның әтисе Вәли, Вәлинең әтисе, миңа бишенче буын тиешле Һади бабам үз мәхәлләләрендә муллалык иткәннәр. Әтиемнең әнисе Хөсникамал әбием исә булачак мәгърифәтче мөгаллим һәм язучы Закир Һади укыган һәм «Яңа әсхабе кяһәф» хикәясендә тасвирланган Тымытык мәдрәсәсендә мөгаллимлек итүче мөдәрриснең кызы була. Бәхранур Вәлиевнең балалары (әтидән кала тагын ике ир һәм ике кыз туган) төпле белем алганнар, русча да укыганнар. Күрше-күлән һәм якын-тирәдә яшәүчеләр русча адрес, белешмә кебек текстларны шулардан яздырганнар. Кепка киеп, европачарак киенеп йөри башлаганлыктан, аларны «урыс Вәли» дип йөрткәннәр. Колхозлашу, күмәк хуҗалыклар төзелү дәверендә үзгәрешләргә сизгер гаилә башлыгы Бәхранур бабам электән төзетеп һәм юнәтелеп килгән каралты-курасын, хуҗалык байлыгын үз ирке белән дәүләткә тапшырган.

Әнием Фатыйма Әүбәкер (Әбүбәкердән кыскартып алынган) кызы (1900 елгы) урта хәлле гаиләдә туып үскән, дүрт кызлы һәм ике уллы ишле гаиләдә ул икенче булып дөньяга килгән. Әнкәй ягыннан мин 7 буын бабамны беләм. Нәсел башында торучы Исмәгыйль Мөслимов дигән иң ерак бабамның нәсел башы, борынгыдан килгән риваять буенча, Казаннан күчеп килгән нәселгә барып тоташкан, шунлыктан Исмәгыйльнең алты улы да (Якуб, Гани, Нәҗми, Кәрим, Җиһангир һәм Әүбәкер бабамның әтисе Әюп) үзләрен Казан кешеләре дип санаганнар. Бу гаилә башлыкларының күпсанлы оныклары һәм алардан тармакланган балаларының байтак өлеше хәзер дә үзебезнең районыбызда яши.

Әниемнең әнисе – әбием Фәрхиҗиһанның чыгышына килгәндә, тумышы белән ул Сарман районына керүче, Мөслимнән 25 чакрымда урнашкан Кәүҗәк авылыннан. Бабам белән әбием ипле гаилә корып, икесе дә яшьләре 90 нан артып киткәнче яшәделәр, 6 бала (4 кыз, 2 ул) тәрбияләп үстерделәр. Бабай өлкән яшендә дә гарәп, латин һәи кириллица графикасындагы текстларны шактый җиңел укучы, русчасын да ярыйсы гына сукалаучы укымышлы карт иде. Үзләренең микрорайонында яшертен генә муллалык вазифаларын башкару белән шөгыльләнсә дә, заман агышын аңлаган аксакал буларак, ул балаларын укытырга, аларга дөньяви белем бирергә омтылган. Шуңа күрә дә 1938 елда ук аның өлкән улы Хафаз абыйның кызыл дипломга Мәскәү университетының механика-математика факультетын тәмамлап чыгуына һәм төрле техникум, училищеларда директор булып эшләвенә, ә икенче улы Сәлах абыйның Актаныш һәм элекке Калинин районнарында милиция начальнигы һәм район башкарма комитеты рәисе вазифаларын башкаруына, ә кызлары Мәрьям белән Закирә апаларның – шәфкать туташы һәм врач, әниемнең укытучы булып китүенә гаҗәпләнергә кирәкми» [33, 133 б.].

Авыр тормыш юлы мотивына нисбәтле фикерләрне Марсель Галиевта да таба алабыз. Ул укытучысының елмаюы артында яшеренгән сагышка игътибар итә һәм: «Тирәндә ниндидер сагыш иңрәп кала иде сыман», – дип яза [28]. Алда әйткәнебезчә, бу җан ярасының сәбәбен галимнең биографиясеннән эзләргә кирәк: Марсель 4 яшендә әтисез калып, ятимлек ачысын татый. 1957 елга кадәр «халык дошманы улы» тамгасы белән яшәргә мәҗбүр була. «Хәтер китабы» мәгълүматларына караганда, аның әтисе, Вәлиев Хәернас Бәхранур улы, 1938 елның 13 ноябрендә кулга алына һәм «икмәк әзерләүгә каршы агитация» өчен хөкем ителә, аннары шул ук елның 28 декабрендә Алабуга төрмәсендә атып үтерелә [38].

Бу факт беренче тапкыр Аяз Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?» (1988–1989) романында мәңгеләштерелә: «Югары авылдан утызынчы еллар башында ничә гаиләне туздырып ташладылар. Утыз җиденең ноябрендә мәктәп директоры Хәернасны юк иттеләр. Хәернас артыннан мәктәпкә педтехникум бетереп, эшкә кайткан ике яшь егет – Хәй белән Фәез юк булды. Авылның сөйкемле хәзрәте Юныс картны төн уртасында җылы түшәгеннән торгызып алып чыгып киттеләр дә шуннан «Алабуга төрмәсендә атканнар икән» дигән шомлы хәбәре генә кайтты. Сиксәнне ашкан бичара картның ни гаебе булды икән?!

«Хәернасны күп белгән өчен, яшь укытучыларны күп сөйләшкән өчен юк иттеләр», – дип гөман кылды куркынган халык һәм озак елларга телен тешләде» [38, 149–150 б.].

Бу фаҗигале факт шулай ук танылган галим-фольклорчының автобиографик повестенда да урын тапкан: «Әтидән мин 4 яшемдә калганмын... Тоталитар режим шартларында, нахак яла ягылып, әтиемнең кулга алынуы һәм «антисоветчик», «халык дошманы» дигән яман исем тагылып, 58 нче иң хәтәр маддә белән хөкем ителүе Зәй районының Югары Баграж авылында урта мәктәп директоры булып эшләгән чагында була» [32, 135 б.]. Марсель Бакиров үз повестенең сәнгать тукымасына әтисенең хаты текстын да кертә:

«Сөекле Фатыймам! Мин әллә исән кайта алам, әллә юк. Мине онытма, моңа кадәр булган тугрылыгыңны сакла. Мин синең гомерлек тормыш иптәшең, дүрт балаңның һәм тиздән туачак балабызның атасы. Үземне түгел, сине мин бик кызганам. Балаларымны бик җәллим, бик сагынам. Минем хакта борчылып, үзеңне бик бетермә. Нишлисең бит, бәла-каза кеше башыннан йөри. Тиз генә кайталмасам, Мөслимгә безнең өйгә кайтырсыз. Балаларга яхшы тәрбия бирергә һәм укытырга тырыш. Минем хакка шулай эшләвеңне телим, шулай булыр дип ышанам» [32, 135 б.].

Гаилә башлыгының төрмәдән җибәргән соңгы хәбәре повестька документальлек, чор сулышын, аның кырыслыгын тоярга мөмкинлек бирә. Нәтиҗәдә, автор бүгенге укучысы өчен шул заман атмосферасын тудыру эффектына ирешә.

Марсель Бакиров турындагы мәкаләләрдә галимнең рухи яктан ирекле шәхес булуы, килешмәгән очракларда җәмәгатьчелек фикеренә каршы тора алуы, үзсүзлеге шактый ассызыклана. Студент чагында ук Марсель Бакировның эксперименталь фонетик тикшеренүләр аша галим буларак танылган укытучысының татар шигърияте турындагы концепциясен кире кагу факты тарихы Казан дәүләт университеты легендасына әверелә: «Хатип Госман зур галим иде. Борынгы көнчыгыш әдәбиятын да, Европаныкын да яхшы белгән галим. Төрле классикларның шигырьләрен яттан сөйләп җибәрүе белән генә дә таң калдыра иде безне. Хәзерге әдәбияттан да яхшы хәбәрдар иде. Мин аның шәкерте булуым белән горурланам. Хатип ага әле яңа гына эшли башлаган чорда университетка кергән студентлар идек без. Укытучыбыз безгә татар шигыре төзелешен рус шигыре теориясенә таянып аңлатты. Басымнар тәртибе сакланган яки очраклы тәңгәл килгән строфаларга таянып, безнең шигырь дә силлабо-тоник төзелештә дип дәлилләргә тырышты. Мин үземнең чыгарылыш хезмәтемдә – диплом эшендә үк бу фикернең ялгыш булуын, татар шигыренең силлабикага, ягъни иҗекләрнең билгеле бер санда чиратлашуына нигезләнә торган ритмик системага корылганлыгын исбатлауны максат итеп куйдым. Бәхетемә, Зәет Мәҗитов белән Хәлиф Курбатов яклап чыктылар, шәкертеңнең карашы ышандыра, диделәр. Ә инде кандидатлык диссертациясе язганда, җитәкчем фикере белән килешмәү гаруз шигырь төзелешенә бәйле рәвештә килеп туды. Атеизм заманы, 37 елгы репрессияләрнең шаһиты булганга күрәдер инде, Хатип ага гарәп-фарсы гарузының төрки гарузы формалашуга йогынты ясаганлыгын танырга теләмәде һәм хәтта әлеге шигырь системасының исемен дә «ачык иҗек шигырь» дип, үзе тудырган термин белән генә атап йөртә иде. Гарәп, диденме, шунда ук ислам дине белән бәйле ассоциация туа бит. Күрәсең, шул өркеткәндер инде яки тайпылыш ясарга этәргәндер. Әмма Хатип аганың гаруз системасын үзләштерергә ярдәм иткән җирле алшартларны ачыклавы, ягъни күпмедер дәрәҗәдә уртак яки тәңгәл күренешләрнең төрки-татар поэзиясендә булуын ачуы, һичшиксез, җитди табыш һәм яңалык иде» [29].

Марсель Бакиров рус әдәбияты тарихчысы, фольклорчы А.Н. Веселовский белән дә бәхәскә керә. Татар галиме тарафыннан күренекле филолог А.Н. Веселовскийның киң таралган «хор синкретизмы», «йола хоры» теориясенә альтернатива-алмаш рәвешендә тәкъдим ителгән «миф-йола синкретизмы» дип аталган яңа реалистик концепциясе, һичшиксез, зур игътибарга һәм тирәнтен өйрәнүгә лаек.

Профессор Тәлгат Галиуллин: «М. Бакиров фәннилеккә зарар китермичә, вакыты белән сәясәтче-дипломат мантиясен киеп алса да, үз фикерен яклаганда, энәләрен тырпайтып куюдан да тартынып тормый», – дип, күзәтүләре белән уртаклаша. Ул моннан тыш, аның көнчыгышны өйрәнүче танылган галимә И. Стеблева белән бәхәскә керүен дә искә төшерә: «Озак еллар дәвамында борынгы төрки шигырен, бигрәк тә Орхон-Енисей ташъязмаларын бәяләүдә И. Стеблева фикере соңгы гыйльми сүз булып бәяләнә килде. М. Бакиров

исә җиңүчегә каршы мәйданга чыккан батыр кебек күренекле тюрколог белән бәхәскә керә, бу борынгы язмалардан шигырь эзләү, аның төзелеш системасын шигырь кануннарына нигезләнеп билгеләргә тырышу урынсыз, ритмик буыннар сизелгәләсә дә (әйтик, нәсердәге шикелле), алар чәчмә белән язылган ядкярләр дип исбатлый», – дигән юллар китерә. [17].

Т. Галиуллин галимнең эрудициясенә дә соклана һәм: «М. Бакировның галим буларак иң көчле ягы: күпләрнең теше үтми торган өлкә – шигырь теориясе, төрки-татар тезмә сәнгатенең килеп чыгу, яшәеш үзенчәлекләрен, метрикасын, строфикасын, рифма-ритм хасиятләренең кабатланмас билге-сыйфатларын ачыклау, шул ук вакытта фольклордан башлангыч алган сәнгати образлар, сурәтләү чараларын һәм иң борынгы тезмә жанрлар системасын тарихи поэтика һәм шигъри үсеш яссылыгында тикшерү, киләчәк перспективаны билгеләү. Инде үткән гасырның җитмешенче елларында ук ул, интуиция белән фаразга гына ышанмыйча, татар-төрки шигыренең төп кануннарын өйрәнүне төгәл фәннәрдәге шикелле үк, эксперименталь җирлектә алып барды.

1972 елда кандидатлык диссертациясенең нигезенә яткан «Эксперименталь тикшеренүләр яктылыгында төрки һәм татар шигырь төзелеше закончалыклары» исемле китабын бастырды. Бу эзләнүләрнең дәвамы буларак, «Фольклор жанрларын системалы итеп тикшерү тәҗрибәсе» (А. Яхин белән берлектә, 1981) [5] һәм «Шигърият дөньясына сәяхәт» (1999) [3] һәм әлегә тиешле бәясен алмаган капиталь һәм масштаблы фикерләве, офык киңлеге белән үтә кыю хезмәт «Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары» (2001) [4] кебек китаплары нәшер ителделәр. Шул рәвешле ул татар шигыренең иң тирәндә, гасырлар түрендә яткан серләрен, чишмә башын эзләүгә гомерен биргән, бик күп тикшерүчеләр кылыч чәкештереп, уртак нәтиҗәгә килә алмаган проблемаларга нисбәтән үз карашын белдереп кенә калмыйча, фәнни табышмакны чишү юлларын да тәкъдим итә, аерым алганда, йола-мифларның поэзия бишеге булуларын исбатлап, татар шигыренең камилләшү, үсү чорында шактый катлаулы юл үтеп, интонацион-синтаксик системаны һәм силлабик ритмны иярләп, гарәп-фарсы телләре аша гаруз үлчәме кабул иткәнче үк, үзебездә «көчәйтелгән басымлы шигырь»нең мөстәкыйль юнәлеш алып, читтән кергән калыпны милли рух белән баетуын дәлилли», дип яза [17].

Марсель Бакиров татар фольклористикасында беренчеләрдән саналган бик саллы «Татар фольклоры» (2008 ел) исеме астында дәреслек тә иҗат иткән галим [7]. Фәнзилә Җәүһәрова фикеренчә, «югары белем бирү уку йотлары студентлары өчен иҗат ителгән ошбу әсбап, тиз арада рус теленә тәрҗемә ителеп, кабат басылды һәм бүгенге көндә ул Казан дәүләт консерваториясе, Казан мәдәният институты студентлары тарафыннан иң актив кулланыла торган уку әсбапларыннан исәпләнә» [15].

Марсель Бакировның каләмдәшләре һәм якташлары сурәтендә үзәк урынны хакыйкать сөюче, ялган диварын җимерүче кеше образы биләп тора: «Марсель Бакиров Уфада «Кызыл таң» гәзитендә эшләгәндә, шундый вакыйга була. Кайсыдыр районнан редакциягә бертуктаусыз хатлар ява башлый. Бер егетне үтергәннәр. Нахак бәла ягып, бөтенләй гаепсез берәүне суд хөкеменә тартканнар. Марсель Бакиров бу районга әллә ничә тапкыр барып кайта, таза хәлле бер төркем, гаепне бүтәннәр өстенә аударып, нык торалар, журналистка янау-кисәтү дә белдерәләр. Әмма Марсель Бакиров дөреслек юлында чигенүне белми. Республика прокурорларын, медицина белгечләрен кузгатып, мәрхүмнең мәетен кабердән казытып алдыра. Кабаттан тикшерүләр башлана һәм гаделлек сагына тәвәккәл-усаллык күрсәтеп, Марсель Бакиров җиңеп чыга: бер гаепсез егетне суд хөкеменнән йолып ала. Юаш, зәгыйфь татар журналистикасында моңарчы күрелмәгән вакыйга, тәвәккәллек үрнәге бит бу!» [27].

Галим олыгая башлагач та, көрәшче сыйфатларын югалтмый. Аның «Татар әдәбияты тарихы» дигән фундаменталь хезмәт концепциясе турындагы соңгы бәхәсен искә төшерү дә җитә [40], [41].

Марсель Бакировның якташлары аның физик көче, егәрлеге турында риваять итеп сөйләрлек вакыйгаларны язалар. Мәсәлән, Ф. Садриев якташы турындагы мәкаләсендә 85 яшьлек галимнең армрестлинг буенча Сабантуйда җиңүче булуы хакында сөйли [28].

Марсель Галиев үзенең очеркында галимне тормыш авырлыгын кичергән, Брежнев торгынлык чоры вәсвәсәләренә бирешмәгән кеше итеп күрсәтә: «Галим булу өчен кешегә нинди сыйфатлар кирәк, дисәләр, мин Марсель Бакировның эшләү һәм яшәү рәвешен күз

алдыма китерәм. Иң беренче сыйфаты, бәлки, үҗәтлектер. Башлаган эшеңне ахырынача алып барып чыгу үҗәтлеге. Тагын... Түзем-чыдам булу һәм фидакарьлек… Күз алдына китерүе дә кыен бит – дөньяда әллә нинди вакыйгалар бара, кешеләр бер-берсе белән ярышып, йортлар сала, машиналар ала, баю юлында шәһит китә, калка, бата язмышлар...

Ә монда, калын стеналар арасында, китапханәнең төп залында кадими китапларга текәлеп, тәүлекләр, айлар, еллар буена фән-белем аланыннан үзеңә нектар җыеп утыр инде! Дөньяның күп кенә рәхәтлекләреннән ваз кичеп, үзеңне «богаулап» фән әсирлегендә тоту – никадәр ихтыяр көче таләп итә торган фидакарьлек, үз-үзеңне аямау түгелмени!» [27].

Мәкалә авторлары укучылары игътибарын М. Бакировны авыр сынаулар сындыра алмавына, киресенчә рухы көче ныгуына юнәлтәләр. Бу, бер яктан, аның характерының ныклыгын, икенче яктан ата-баба мирасын өйрәтергә, якларга, коткарырга, милли мәдәниятнең казанышлары өчен горурлык хисләрен киләчәк буыннарга җиткерергә омтылуын аңлата. Марсель Бакировның гомумтөрки поэзиянең яралуын һәм иң борынгы формаларын өйрәнүгә багышланган монографиясе белән танышкач, академик Мансур Хәсәнов үзенең бәяләмәсендә галимнең эш нәтиҗәләре белән соклануын яшермичә: «Әмма моңарчы бу кадәр ерак заманнарга һәм тирәнгә, ягъни бабаларыбыз тудырган шигъри-поэтик иҗатның пратөрки дәверенә, яралгы-эмбрион хәлдәге чорына берәүнең дә игътибар иткәне һәм үтеп керә алганы юк иде әле. Чөнки борынгы язма ядкярләрнең конкрет иҗат ителү вакыты, гадәттә, фәнни тикшеренүләрнең хронологик кысаларын чикли, әлеге чикнең аръягына күп филологлар күз сала алмый», – дип яза [20].

2019 елда Татарстан китап нәшриятында Марсель Хәернас улы Бакировның «Прототюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура» (2019) дигән фундаменталь хезмәте дөнья күргән иде [11]. Биредә ул күп көч куеп, үзе туплаган лексик-семантик һәм өлешчә этимологик чагыштырма сүзлек материалларына таянып үзен, иң борынгы түркләр һәм аларның телләре, фәндә хаклы рәвештә урын дәгъвалаган концепция авторлары карашынча, Алтайда түгел, бәлки Якын Көнчыгышта, ягъни Азия кыйтгасының көньяк-көнбатыш өлешендә формалаша башлаган дигән теория тарафдары буларак танытты. Әлеге хезмәтендә тюрколог галимебез түркләрнең этногенезы һәм борынгы этник тарихы ике зур этаптан торганлыгын ышандырырлык итеп дәлилле раслый алды. Шул исәптән Якын һәм Алгы Көнчыгышта узган башлангыч этапта түрк баба теленең һәм иң элгәреге түркләрнең үле яки борынгы этник төркемнәр катнашлыгында ничек яралганлыгын ачыклауга үзеннән зур өлеш кертте [25].

Узган ел Татарстан китап нәшриятында күренекле галимнең борынгы бабаларыбызның килеп чыгышын тел күрсәткечләре яссылыгында тикшерүгә багышланган тагын бер саллы китабы басылып чыкты: «Тайны происхождения наших предков. Историко-лингвистическое исследование» [12]. Бу хезмәткә бәйле җитди фикерне танылган археолог, академик Ф. Хуҗин әйтте. Ул: «Профессор М. Бакировның ачышлары төрки халыклар анаватанын, алда әйтелгәнчә, Алтай-Саян җирләре белән бәйләүче, шулай ук чуваш теленә хас *р*-сөйләше, имеш, иң борынгы төрки телләрдә үк барлыкка килгән, *з*-сөйләше исә баштарак чорларда, гомумән, булмаган дип инанучы тюркологларның фаразга корылган карашларын нык какшата һәм кискен кире кага. Әлеге монографиядә төрки этногенезының Якын Көнчыгышка мөнәсәбәтле башлангыч чорын з-телле прототөркиләр белән, ә *р*-тел сөйләше барлыкккa килгән урынны Каспий-Арал (Туран) төбәге белән бәйләп аңлатуны һәм дә моны үзе туплаган лексик-семантик чагыштырма сүзлек материаллары һәм үзе аерып чыгарган тотрыклы «милли»-этник сыйфатларга нигезләп исбатлауны мин олуг галимебезнең иң зур ачышы-казанышы дип саныйм», – дип язып чыкты [25].

Галимнең меңгә якын иң борынгы лексик берәмлекләрне эченә алган чагыштырмалы сүзлеге генә түгел, ә аерым сүзләрнең, шул исәптән ономастик тәңгәллекләрнең килеп чыгышына, генетик яки элемтә-контактка нигезләнгән охшашлык-уртаклыкларга мөнәсәбәтле тикшеренүләре дә җитди игътибарга лаек [24], [25].

Академик Ф. Хуҗин: «Галимнең «Кыйсса-и Йосыф» поэмасының Урта Азиядә түгел, ә үзебезнең болгар-татар җирлегендә иҗат ителгәнлеген исбатлауга багышланган фәнни эзләнүләре, күзәтүләре – укучы игътибарын нык җәлеп итә торган үзе бер дөнья!» – дигән нәтиҗә дә ясый [25].

Соңгы елларда күренекле галим үзен язучылык өлкәсендә сынап карый. «Хан кызы»

– танылган фольклорчы, әдәбият белгече М. Бакировның беренче пьесасы [43]. М. Хәбетдинова фикеренчә, «пьеса «җырлый торган драма»ның якты үрнәге булып тора, анда, мелодрамага хас булганча, «коткаручы» газап чигүче җанны әсирлектән азат итә. «Хан кызы» мелодрамасын интриганың тармакланган системасы, конфликтлар төзүдәге осталык, персонажларның «сүзләр уенына корылган» үткен әңгәмәләре аерып тора. Шул ук вакытта әсәрдә халыкчан юмор да җитәрлек. Пьесаның күркәм сыйфатларыннан берсе – аның саф татар телендә язылуы. Мондый җанлы татар сөйләменә корылган замана әсәрләре – бүгенге көндә гаять сирәк күренеш» [44].

Соңгы елларда М.Х. Бакиров үзен проза әсәрләре авторы буларак та таныта башлады. Аның «Итек» (хикәя) [45], «Кара таплы бәхет» (бәян) [32], [33] кебек әсәрләре язучы Габдулла Тукай («Исемдә калганнар») [42] иҗатына барып тоташкан татар әдәби традициясен дәвам итү үрнәге булып торалар. Марсель Бакировның истәлекләре Бөек Ватан сугышы чоры һәм сугыштан соңгы еллар тормышы көндәлеге ролен уйный. Илгә килгән фаҗига бала күзлегеннән оста итеп сурәтләнгән. «Кара таплы бәхет»кә килсәк, ул – юморның иң авыр шартларда яшәргә ярдәм итүен күрсәткән бәян. Марсель Бакиров бу әсәре белән үз буынының коллектив портретын тудыруга ирешә.

**Нәтиҗә**

Югарыдагы тикшеренүләребезгә таянып, түбәндәге нәтиҗәләргә килдек.

XX гасырның икенче яртысыннан алып – XXI гасырның беренче чирегенә кадәрге диярлек вакыт аралыгында хезмәт куйган талантлы фән эшлеклеләре плеядасы вәкилләренең берсе булган Марсель Бакиров – замандашлары, укучылары, каләмдәшләре, хезмәттәшләре тарафыннан шактый бәяләнгән шәхес. Әлеге бәяләмәләр шәхеснең бала чагы, студент чоры, югары уку йорты укытучысы, туктаусыз эзләнүче галим кебек портретларын тудырган чыганаклар буларак бәяләнә алалар. Шулар бәрабәренә бер гасырлык дәвердә яшәгән буынның коллектив портретын да сурәтләргә мөмкинлек тудырыла. Алар аркылы авыр тормыш сынаулары аша үткән, тотрыклы үз фикере булган, үҗәт олпат шәхес образын күрә алабыз.

**Әдәбият**


1. *Бакиров М. Х.* Закономерности тюркского и татарского стихосложения в свете экспериментальных исследований: дис. ... канд. филол. наук: 10.00.00. Казань, 1972. 306 с.
2. *Бакиров М. Х* Генезис и древнейшие формы общетюркской поэзии : дис. ... докт. филол. наук: 10.01.02. Казань, 1999. 389 с.
3. *Бакиров М. Х.* Шигърият дөньясына сәяхәт: Фольклордан язма шигырьгә күчеш тарихыннан / М. Бакиров. Казан: ТГЖН, 1999. 240 б.
4. *Бакиров М.Х.* Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан: Мәгариф, 2001. 343 б.
5. *Бакиров М. Х.* Древнетюркская поэзия: неразгаданные тайны устного и письменного поэтического творчества наших предков Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. 389 с.
6. *Яхин А., Бакиров М.* Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе: (Мәзәкләр, бәетләр). Казан: Казан ун-ты нәшр., 1979. 198 с.
7. *Бакиров М. Х.* Котлы булсын туегыз! Казан: Сүз, 2007. 189 б.
8. *Бакиров М. Х.* Татар фольклоры / М. Х. Бакиров. Казан: Мәгариф, 2008. 359 б.
9. *Бакиров М. Х.* Татарский фольклор: монография. Казань: Ихлас, 2012. 399 с.
10. *Бакиров М. Х.* Татарский фольклор / М. Бакиров. Казань: Ихлас, 2013. 400 с.
11. *Бакиров М. Х.* Татарский фольклор. 2-е изд., доп. Казань: 2018. 406 с.
12. *Бакиров М. Х.* Прототюрки [Текст]: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура: Казань: Татарское кн. изд-во, 2019. 462 с.
13. *Бакиров М. Х.* Тайны происхождения наших предков: Казань: Татарское кн. изд-во, 2022. 391 с.
14. *Шәрипов Ә.* Шундый татар тюркологы бар // Мәдәни җомга. 2003. №12
15. *Шәрипов Ә.* Олпат остаз һәм олуг галим // М. Х. Бакиров Шәхес. Галим. Остаз. Казан: Сүз, 2008. 4–23 б.
16. *Җәүһәрова Ф.* Чын галимнең сүзе калыр, җуелмаслык эзе калыр // Безнең мирас. 2019. № 2.
17. *Харрасова Р. Ф.* Пионер-исследователь древнетюркской поэзии: к 80-летию М. Х. Бакирова // Вестник ТГГПУ, 2013. № 3 (33). С. 346–348.
18. *Галиуллин Т.* Шигъри җан аһәңе // Казан утлары. 2009. № 9.
19. *Дәүләтшин Г.* Прототюрки бабаларыбызга юл яручы китап // Казан утлары, 2019 ел. № 7.
20. *Мухаметдинов Р.* «Сенсационная книга татарского тюрколога...» // Звезда Поволжья. 2020. № 7.
21. *Хәсәнов М.* «Бу кадәр тирәнгә берәүнең дә үтеп кергәне юк иде әле» // Мирас журналы. 2002 ел. № 6.
22. *Садриев Ф.* Шигърият бишеген тибрәтүче галим // Мәдәни җомга. 2013. № 49.
23. *Шәрипов Ә.* Үлемсез хәзинәбезгә лаек хезмәт // Мәдәни җомга. 2009. 18 декабрь.
24. *Тариел Азертюрк* О вкладе татарского тюрколога в ориенталистику (Рецензия на моногра-

фию профессора М. Х. Бакирова «Прототюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура». Казань, 2019. 464 с.) // Филология и культура. Philology and culture. 2021. № 4 (66). С. 282–285.

25. *Тагиров И.* Новая монография профессора Марселя Бакирова // Звезда Поволжья. 2022. № 38.

26. *Хузин Ф.* Болгар, чуваш, татарларның этногенетик үзенчәлекләре (Профессор М.Бакировның «монографиясен укыганда туган фикерләр) // Фәнни Татарстан. 2023. № 1. С. 164–172

27. *Вәли Р.* Җылантау // Мәдәни җомга. 2017 ел. №19.

28. *Галиев М.* Кәүсәр суы эзләп // Мәдәни җомга. 2003. №12.

29. *Садриев Ф.* Галимнең ике җиңүе // Безнең мирас. 2019. №4.

30. Чын фольклорчы һәм шигърият белгече / М. Бакиров белән Р. Рахман әңгәмәсе // Шәһри Казан. 2014. апрель.

31. *Бакиров М. Х.* Шәхес. Галим. Остаз. Казан: Сүз, 2008. 80 б.

32. *Бакиров М. Х.* Мең дә бер фикер. Казан: Халкыбыз мирасы нәшрияты, 2023. 536 б.

33. *Бакиров М.* Кара таплы бәхет (Биографиям, тормыш һәм хезмәт юлым турында бәян) // Казан утлары. 2023. № 11. 132–159 б.

34. *Бакиров М.* Кара таплы бәхет (Биографиям, тормыш һәм хезмәт юлым турында бәян) // Казан утлары. 2023. № 12. 127–149 б.

35. *Нигматуллина Ю. Г.* Методология комплексного изучения художественного творчества. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1983. 104 с.

36. *Коган М. С.* Человеческая деятельность. Опыт системного анализа. М.: Политиздат, 1974. 328 с.

37. *Нигматуллина Ю. Г.* Системно-комплексное исследование художественного творчества: история научного направления в Казанском университете. Казань: Фэн, 2004. 249 с.

38. Жертвы политического террора в СССР. URL: https://base.memo.ru/person/show/498556?ysclid=lnmvo78ssq752355983 (мөрәҗәгать итү вакыты: 09.10.23).

39. *Гыйләҗев А. М.* Балта кем кулында? Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 320 б.

40. *Бакиров М.* Үчлек белән үрелгән түрәлек // Мәдәни җомга. 2023. №7. 22 февраль.

41. *Бакиров М.* Сюрприз һәм яңа сигезтомлык // Безнең гәҗит. 2023. №13. 5 апрель. URL: https://beznen.ru/archive/zhan-avazy/070423/syurpriz-hm-yana-sigeztomlyk (мөрәҗәгать итү вакыты: 09.10.23).

42. *Тукай Г. Исемдә калганнар // Тукай Г.* Әсәрләр / төз.: Гали Халит, Рашат Гайнанов, Лена Гайнанова, Рәис Даутов. Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. Т. 5.

43. *Бакиров М. Х.* Хан кызы // Казан утлары. 2020. № 6. Б. 107–139.

44. *Хәбетдинова М. М.* «Үз өлешем« / М. Бакировның «Хан кызы» пьесасына рецензия / М. М. Хәбетдинова // Казан утлары. 2020. №6. Б. 175–177.

45. *Бакиров М. Х.* Итек. Хикәя // Казан утлары. № 8. Б. 98–104.

46. Российские фольклористы: справочник / Центр традиц. рус. культуры «Преображенское», Арх. «Фольклор России»; [сост. Л. В. Рыбакова]. Москва: Индрик, 1994. 206 с.

# ТВОРЧЕСКИЙ ПОРТРЕТ ФОЛЬКЛОРИСТА МАРСЕЛЯ БАКИРОВА В ЗЕРКАЛЕ ЕГО ЛИЧНЫХ ВОСПОМИНАНИЙ И В ОЦЕНКЕ СОВРЕМЕННИКОВ

**Гюлшах Йылмаз,**
Университет Афьон Коджатепе,
Turkey, 0300, Afyonkarahisar/Center,
gulsahyilmaz4048@gmail.com.

**Фанзиля Хакимовна Завгарова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
zavgarova@inbox.ru.

**Милеуша Мухаметзяновна Хабутдинова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
mileuscha@mail.ru.

В статье систематизирован круг научных статей, посвященнных жизни и деятельности известного фольклориста, доктора филологических наук, профессора Марселя Хаернасовича Бакирова (род. 1933). Раскрыты разные грани его научной и творческой деятельности. Исследование велось с помощью биографического и культурно-исторического методов. В статье сформирована библиография работ об ученом.

**Ключевые слова**: татары, татарские ученые, фольклористика, Марсель Бакиров, Казанский университет